**Габдулла Тукай бәйрәме!**

26нчы апрель, Габдулла Тукайның Туган көненә багышланган чаралар укучылар өчен дә, укытучылар өчен дә бай мәгълүматлы булып узды. Иртән дәресләр башланыр алдыннан 5нче сыйныф укучылары сыйныф җитәкчесе Альбина Маликовна  белән лицейга керү ишекләре янында каршылап, кергән һәрбер кешене бәйрәм белән котлап, тематикага туры килә торган кызыклы сораулар биреп каршы алдылар. Һәм бүләк итеп укучылар үз куллары белән ясаган Г.Тукай фоторәсеме төшкән медальон бүләк итә бардылар. Каршы алып торучы укучылар татар милли киемнәреннән, кәләпүш – калфаклар киеп бик күркәм булып чын бәйрәм хисен тудырдылар. Габдулла Тукайның “Бәйрәм бүген” дигән шигыре нәкъ безнең лицей мөхитенә туры килде. Бәйрәм белән, Дуслар!